# Балалар өчен җырлар һәм уеннар



0+

ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ

УДК 821.512.145-1-93:372
ББК 84(2Рос=Тат)-5:74.1
Б20

Төзүчесе *Лилия Дәүләтшина*

**Балалар өчен җырлар һәм уеннар** : биш-алты яшьлек ба-
Б20 лалар өчен бармак уеннары, табышмаклар, тизәйткечләр / [төз.
Л. Дәүләтшина ; рәссамы Т. Вазиев]. — Казан : Татар. кит. нәшр.,
2018. — 63 б. : рәс. б-н.
ISBN 978-5-298-03644-3

Китап балаларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып төзелгән һәм, төзүченең моңа кадәр чыккан басмаларының дәвамы буларак, 5–6 яшьлек балаларга адреслана. Ата-аналарга, тәрбиячеләргә ярдәмлек буларак тәкъдим ителә.

УДК 821.512.145-1-93:372
ББК 84(2Рос=Тат)-5:74.1

ISBN 978-5-298-03644-3

© Татарстан китап нәшрияты, 2018
© Дәүләтшина Л. Х., төзү, 2018

# Эчтәлек

## ЕЛ ФАСЫЛЛАРЫ


Көз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 3
Кыш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 6
Яз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 9
Җәй . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 11


## ТЕРЕК ТАБИГАТЬ


Бөҗәкләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 14
Кыргый хайваннар . . . . . . . . . . . . . . . 17
Җылы як хайваннары . . . . . . . . . . . . . 20
Йорт хайваннары . . . . . . . . . . . . . . . . 22
Кошлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 25
Йорт кошлары . . . . . . . . . . . . . . . . . . 28


## ТЕРЕК БУЛМАГАН ТАБИГАТЬ


Җиләк-җимеш . . . . . . . . . . . . . . . . . . 31
Яшелчәләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 34
Гөмбәләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 36
Җиләкләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 38
Чәчәкләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 40
Агачлар, куаклар . . . . . . . . . . . . . . . 42

## БЕЗНЕҢ ЙОРТ

Йорт җиһазлары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 44
Савыт-саба. Азык-төлек . . . . . . . . . . . . . . 46
Эш кораллары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 48
Гаиләм һәм мин . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 50
Тән әгъзалары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 52
Өс-баш киемнәре . . . . . . . . . . . . . . . . . . 54
Аяк киемнәре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 56
Уенчыклар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 58
Машиналар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 60

# ЕЛ ФАСЫЛЛАРЫ

# КӨЗ

## БАРМАК УЕННАРЫ

### Яфрак бәйрәме



Сары, сары, сап-сары
Агачның яфраклары.
Җил исә, ява яфрак –
Көзнең матур чаклары...

*Л. Лерон*





Үтте-китте матур җәйләр,
Көзләр килеп җиттеләр.
Ак каенның яфраклары
Саргаешып киптеләр.

*К. Нәҗми*

# СҮЗЛЕ-ХӘРӘКӘТЛЕ УЕННАР



Җәй үткәчтен, килә көз.
*(кулларны җәеп күрсәтергә)*
Көзне шуннан беләбез –
Саргая куак, агач,
*(бармакларны агач кебек
итеп күрсәтергә)*
Кырлар кала ялангач.
*(кулларны аска төшереп
селкергә)*

*Р. Корбан*

## Кояшны сагыну

Көн дә соры, моңсу никтер,
*(куллар белән һавада
түгәрәк ясарга)*
Ә кояш кая киткән?
*(кулларны җәяргә,
башны як-якка боргаларга)*
Әллә качып елый микән? –
*(күзләрне елаган сыман уарга)*
Яңгыр сибәли күктән.
*(яңгыр яуган сыман,
бармакларны өстән аска
селкетеп төшерергә)*

*Л. Шәех*

## ТАБЫШМАКЛАР

### Бу кайчак була?

Кырлар буш кала,
Яңгырлар ява,
Җирләр дымлана –
Бу кайчак була? *(әнөн еөд)*

*Г. Тукай*

Җиләс җилләр
Исеп килә,
Җилдән алма
Исе килә.
Шатланабыз без,
Юмарт та соң ... ! *(еөд)*

*Ш. Галиев*

## ТИЗӘЙТКЕЧЛӘР

### Алма коела

Көзге төн.
Тып та тып...
Алмалар коела.
Мондый төн
Тылсымлы
Төн кебек тоела...

*Г. Гыйльманов*

